МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ
И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН
ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ
ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.07.2017 № 466

г.Казань

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2017 елның 1 августында теркәлде, № 4038

Татарстан Республикасында социаль хезмәт җиткерүчеләр реестрына кертелгән, ләкин дәүләт биремен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәт җиткерүчеләрнең чыгымнарын компенсацияләүгә (түләүгә) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирү өчен кулланыла торган документларның формаларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында социаль хезмәт җиткерүчеләр реестрына кертелгән, ләкин дәүләт биремен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәт җиткерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының көчен югалтуын тану турында" 2016 елның 29 декабрендәге 1046 номерлы карарын үтәү максатында боерык бирәм:

1. Расларга:

1 нче кушымтага туры китереп, социаль хезмәтләр күрсәтелүгә бәйле рәвештә чыгымнарны компенсацияләүгә (түләүгә) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирелү турында килешү төзүгә заявка формасын;

2 нче кушымтага туры китереп, социаль хезмәтләр күрсәтелүгә бәйле рәвештә чыгымнарны компенсацияләүгә (түләүгә) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирелү турында килешү формасын.

2. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министр урынбасары Э.Н. Нигъмәтҗанованы җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 13.07.2017 № 466 боерыгына
1 нче кушымта

Рәвеше

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының____________________________ ________________________________муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) социаль яклау идарәсе (бүлеге) башлыгына

## Социаль хезмәтләр күрсәтелүгә бәйле рәвештә чыгымнарны компенсацияләүгә (түләүгә) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирелү турында килешү төзүгә ЗАЯВКА

________________________________________________________________________

(җиткерүченең аталышы

__________________________________________________________________белән

(оешма исеме, шәхси эшкуарның ф.и.а.)

социаль хезмәтләр күрсәтелүгә бәйле рәвештә чыгымнарны компенсацияләүгә (түләүгә) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирелү турында килешү төзүне сорыйм.

Түбәндәге мәгълүматларны хәбәр итәбез:

1. Тулысынча аталышы ________________________________
2. Урнашу урыны ________________________________
3. Почта адресы ________________________________
4. Электрон почта адресы ________________________________
5. Телефоны, факсы ________________________________
6. ОГРН (ОГРНИП) ________________________________
7. ИНН ________________________________
8. КПП ________________________________
9. ОКТМО ________________________________
10. ОКАТО ________________________________
11. Банк реквизитлары:
    - банкның аталышы ________________________________
    - исәп-хисап счеты ________________________________
    - банкның корреспондент счеты ________________________________
    - Банкның ИНН/КПП ________________________________

Шушы заявкада һәм аңа теркәлә торган документларда булган мәгълүматларның дөрес һәм тулы булуын раслыйм.

Төгәл булмаган мәгълүматларны һәм документларны тапшырган өчен җаваплылык турында кисәтелдек.

Грант алу максатларында төгәл булмаган мәгълүматлар тапшырылган очракта, шулай ук хата ачыклану нәтиҗәсендә грантны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтарып бирергә мәҗбүр булуыбыз турында кисәтү ясалды.

Бу заявканы һәм аңа теркәлә торган документларны карап тикшерү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматларны түбәндәге адрес буенча җибәрүне сорыйм (кирәклесен V тамгасы белән билгеләргә):

Почта ☐

электрон почта ☐

Заявкага түбәндәгеләр теркәлә:

| № п/п | Документларның аталышы | Саны | |
|---|---|---|---|
| | | данә | бит |
| 1. | | | |
| 2. | | | |
| 3. | | | |
| 4. | | | |
| 5. | | | |
| 6. | | | |
| 7. | | | |

"____"______________ 20 ___ел. ____________________ ____________________________
*(дата)* *(гариза бирүченең имзасы)* *(имзаның аңлатмасы)*

*М.У.* (Россия Федерациясе законнарында эш бирүче өчен мөһер булдыру бурычы билгеләнгән очракларда).

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

**Язу-белдерүнамә**

Заявка һәм документлар кабул ителде ______________________________

Заявканы теркәү номеры

______________

Заявканы һәм документларны кабул итү датасы

______________
*(көне, ае, елы)*

Социаль яклау идарәсе (бүлеге) хезмәткәренең имзасы

______________________

имзаның аңлатмасы

______________________

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 13.07.2017 № 466 боерыгына
2 нче кушымта

Рәвеше

Социаль хезмәтләр күрсәтелүгә бәйле рәвештә чыгымнарны компенсацияләүгә (түләүгә) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирелү турында №_______
КИЛЕШҮ

Казан ш. "__" ___________ 201 ел.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, алга таба "Министрлык" дип исемләнүче,_______________ ______________________________________________________________ исеменнән,
(вәкаләтле затның вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)
________________________________________________________нигезендә гамәл йөртүче,
(документның аталышы һәм реквизитлары)
бер яктан, һәм _________________, алга таба "Җиткерүче" дип исемләнүче, икенче яктан, ___________________исеменнән, ______________________________________
(Устав һәм башкалар)
нигезендә гамәл кылучы, икесе бергә "Тарафлар" буларак исемләнүчеләр, Җиткерүченең 20___елның "___"_________ №____ заявкасы нигезендә шушы Килешүне төзеделәр, түбәндәгеләр хакында:

## I. Килешүнең предметы

1.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында социаль хезмәт җиткерүчеләр реестрына кертелгән, ләкин дәүләт биремен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәт җиткерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының көчен югалтуын тану турында" 2016 елның 29 декабрендәге 1046 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт җиткерүчеләр реестрына кертелгән, ләкин дәүләт биремен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәт җиткерүчеләрнең чыгымнарын компенсацияләүгә (түләүгә) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирү тәртибе (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 29.12.2016 № 1046 карары

белән расланган Тәртип) һәм шушы Килешү нигезендә Министрлык Җиткерүчегә түләүсез яисә өлешчә түләүгә социаль хезмәтләр күрсәтелүгә бәйле рәвештә чыгымнарны компенсацияләүгә (түләүгә) субсидия рәвешендә грант (алга таба – Грант) бирүне гамәлгә ашыра.

1.2. Грант бирүне финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан Министрлыкка каралган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла.

1.3. Финанслау чыганагы: Татарстан Республикасы бюджеты.

## II. Грант күләмен билгеләү

2.1. Җиткерүчегә күчерелергә тиешле грант күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$S_i = \sum ((P_j*T)–O_j),$$

биредә:

$S_i$– i-нче социаль хезмәт җиткерүчегә грант күләме;

$P_j$– j-нче социаль хезмәтләр алучыга социаль хезмәтләр күрсәтелү турында шартнамә нигезендә күрсәтелгән социаль хезмәтләр саны;

T – социаль хезмәткә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан расланган тариф;

$O_j$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Социаль хезмәтләр күрсәтелгән өчен түләү күләмен һәм аны алу тәртибен раслау турында" 2014 елның 29 ноябрендәге 927 номерлы карары нигезендә хосусый программа нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтелү турында шартнамә нигезендә күрсәтелгән социаль хезмәтләр өчен j-нче социаль хезмәтләр алучы тарафыннан түләнергә тиешле сумма.

Аналогик хезмәтләргә Җиткерүченең тарифлары Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан расланган тарифлар дәрәҗәсеннән югары булган очракта, грант күләмен исәпләп чыгарганда Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты раслаган тарифлар кулланыла.

Әгәр дә аналогик хезмәтләргә Җиткерүченең тарифлары Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты раслаган тарифлар дәрәҗәсеннән кимрәк булса, грантны исәпләп чыгарганда Җиткерүче тарафыннан расланган тарифлар кулланыла.

Социаль хезмәтләр алучыга күрсәтелгән социаль хезмәтләрнең фактик күләме социаль хезмәтләр күрсәтелү турында шартнамәдә билгеләнгән хезмәтләр күләменнән азрак булса, грант күләме күрсәтелгән хезмәтләрнең фактик күләменнән чыгып билгеләнә.

Шушы Килешүнең 3.3 пунктының икенче абзацы нигезендә грант алу өчен документлар тапшырылган очракта, Җиткерүчегә күчерелергә тиешле грант күләмен билгеләү социаль хезмәтләр күрсәтелгән елда гамәлдә булган тарифлар буенча гамәлгә ашырыла.

2.2. Социаль хезмәтләр алучы тарафыннан түләнергә тиешле сумма социаль хезмәтләрне күрсәткән өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Социаль хезмәтләр күрсәтелгән өчен түләү күләмен һәм аны алу тәртибен раслау турында" 2014 елның 29 ноябрендәге 927 номерлы карары һәм социаль хезмәтләр

күрсәтелү турында шартнамә нигезендә билгеләнгән түләү зурлыгына туры китереп билгеләнә.

## III. Грант бирү шартлары һәм тәртибе

3.1. Шушы Килешү шартлары нигезендә грант бирү 20___елның "__" _________ башлап 20___ елның 31 декабренә кадәрге чорда күрсәтелгән социаль хезмәтләр өчен шушы Килешүнең 2.1 пунктына туры китереп билгеләнә торган зурлыкта гамәлгә ашырыла.[1]

3.2. Грант күчерү өчен Җиткерүче үзенең эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) социаль яклау идарәсенә (бүлегенә) (алга таба – территориаль социаль яклау органы) шушы Килешүгә 1 нче кушымтага туры китерелгән формада грант күчерүгә гаризаны оешманың җитәкчесенең имзасы һәм мөһере (Россия Федерациясе законнарында мөһер булдыру бурычы йөкләнгән булу очракларында) белән таныклап тапшыра, түбәндәге документларны теркәп:

1) шушы Килешүгә 2 нче кушымтага туры китерелгән формада социаль хезмәтләр алучылар реестрын, оешма җитәкчесенең имзасы һәм мөһере (Россия Федерациясе законнарында мөһер булдыру бурычы йөкләнгән булу очракларында) белән таныклап;

2) Җиткерүче тарафыннан таныкланган рәвештә:

социаль хезмәтләр алучы белән шартнамә күчермәсен (ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтүдән тыш). Алга таба грант күчерелү буенча мөрәҗәгать иткәндә Җиткерүче шул бер үк хезмәтләр алучыга карата шартнамә күчермәләрен бары тик шартнамәгә үзгәрешләр кертелү очрагында гына аңа өстәмә килешүне теркәп тапшыра;

социаль хезмәтләр алучы һәм Җиткерүче тарафыннан имзаланган күрсәтелгән хезмәтләрне тапшыру-кабул итү акты күчермәсен;

3) шушы Килешүгә 3 нче кушымтага туры китерелгән формада Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант күчерелүгә белешмә-хисапнамә, оешма җитәкчесенең имзасы һәм мөһере (Россия Федерациясе законнарында мөһер булдыру бурычы йөкләнгән булу очракларында) белән таныклап;

4) социаль хезмәтләр алучының җан башына уртача кереме шуларга нигезләнеп хисаплап чыгарылган документларның күчермәләрен.

Гариза һәм документлар территориаль социаль яклау органына язмача рәвештә шәхсән тапшырыла яисә почта аша хат итеп яки электрон имза белән имзаланган электрон рәвешендә җибәрелә. Гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) электрон документлар рәвешендә җибәргән очракта, әгәр дә алар "Электрон имза турында" 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм "Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 21.1 һәм 21.2 статьялары таләпләренә туры китереп имзаланмаган булсалар, грант

---

[1]Чор бер финанс елы чикләрендә күрсәтелә

күчерү Җиткерүче тарафыннан территориаль социаль яклау органына шушы Тәртипнең 3.2 пунктында күрсәтелгән документларның төп нөсхәләре яисә аларның законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланган кәгазьдәге күчермәләре тапшырылганда гына гамәлгә ашырыла. Шул ук вакытта грант күчерелү буенча мөрәҗәгать итү көне булып территориаль социаль яклау бүлеге тарафыннан күрсәтелгән документлар кәгазьдә алынган көн санала.

Тапшырылган, субсидия түләү өчен нигез булып хезмәт итүче мәгълүматларның һәм документларның дөрес һәм тулы булуы өчен җаваплылык Җиткерүчегә йөкләнә.

3.3. Шушы Килешүнең 3.2 пунктында каралган документлар грант алу өчен, ай саен, айның 20нче көненә кадәр, агымдагы елның 15 декабреннән соңга калмыйча тапшырылырга мөмкин.

Шушы Килешүнең 3.2 пунктында каралган, 15 декабрьдән соң күрсәтелгән социаль хезмәтләр өчен грант алу буенча документлар территориаль социаль яклау органына социаль хезмәтләр күрсәтелгән елдан соң килүче елның 12 гыйнварына кадәр тапшырыла.

3.4. Территориаль социаль яклау органы Җиткерүче тапшырган документларны, грант зурлыгы исәпләмәсен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 29.12.2016 № 1046 карары белән расланган Тәртипнең 3.3 пункты нигезендә тикшерә һәм шушы Килешүнең 3.2 пунктында күрсәтелгән документлар Җиткерүче тарафыннан тапшырылган көннән соңгы 10 эш көненнән соңга калмыйча грант күчерү турында яисә аны күчерүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Грант күчерү турында яисә грант күчерүдән баш тарту турында карар Җиткерүчегә язмача рәвештә карар кабул ителгән көннән соңгы 5 эш көне эчендә шушы Килешүгә 4 нче кушымтада күрсәтелгән формага туры китереп хәбәр ителә.

Территориаль социаль яклау органы грант күчерү турында карар кабул ителгәннән соңгы 5 эш көне эчендә социаль хезмәтләр өчен грант күчерелүгә реестрны, шушы Килешүгә 5 нче кушымтага туры китерелгән формада төзелгән, территориаль социаль яклау органы башлыгы тарафыннан имзаланган рәвештә, раслау өчен Министрлыкка тапшыра.

Шушы Килешүнең 3.3 пунктындагы икенче абзацында каралган очракта, территориаль социаль яклау органы социаль хезмәтләр өчен Җиткерүчегә грант күчерүгә реестрны, социаль хезмәтләр күрсәтелгән елдан соң килүче елның 25 гыйнварына кадәр, раслау өчен Министрлыкка тапшыра.

3.5. 15 декабрьдән соң күрсәтелгән социаль хезмәтләр өчен Җиткерүчегә грант күчерү социаль хезмәтләр күрсәтелгән елдан соң килүче елның 1 февраленә кадәр социаль хезмәтләр күрсәтелгән елда гамәлдә булган тарифлар буенча агымдагы финанс елында каралган акча чикләрендә башкарыла.

3.6. Җиткерүчене социаль хезмәт җиткерүчеләр реестрыннан төшереп калдырган очракта, шушы Килешү нигезендә грант түләү аны реестрдан төшереп калдыру мизгеленә кадәр күрсәтелгән хезмәтләр өчен шушы пунктта билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып башкарыла.

Җиткерүчене социаль хезмәт җиткерүчеләр реестрыннан төшереп калдырган очракта Җиткерүче территориаль социаль яклау органына аны реестрдан төшереп калдырган көнгә кадәр күрсәтелгән социаль хезмәтләр өчен грант алу буенча

документларны аны әлеге реестрдан төшереп калдырган көннән соңгы 10 эш көне эчендә үзенең эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча территориаль социаль яклау органына тапшыра. Шул ук вакытта, әгәр дә Җиткерүче социаль хезмәт җиткерүчеләр реестрыннан 16 декабрьдән 31 декабрьгә кадәр булган чорда төшереп калдырылса, ул вакытта 15 декабрьдән соң күрсәтелгән социаль хезмәтләр өчен грант алу буенча шушы Килешүнең 3.2 пунктында каралган документлар территориаль социаль яклау органына социаль хезмәтләр күрсәтелгән елдан соң килүче елның 12 гыйнварына кадәр тапшырыла һәм акча күчерү агымдагы финанс елында каралган акча чикләрендә башкарыла.

Социаль хезмәт җиткерүчеләр реестрыннан төшереп калдырылган Җиткерүчегә күрсәтелгән хезмәтләр өчен грант территориаль социаль яклау органы Җиткерүчегә социаль хезмәтләр өчен грант күчерүгә реестрны шушы Килешүгә 5 нче кушымтага туры китереп төзелгән, территориаль социаль яклау органы башлыгы тарафыннан имзаланган рәвештә Министрлыкка раслау өчен тапшырган көннән соңгы 5 эш көне эчендә күчерелә.

## IV. Тарафларның бурычлары

4.1. Министрлык түбәндәгеләрне үтәү бурычын үз өстенә ала:

4.1.1. Грант бирелүнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 29.12.2016 № 1046 карары белән расланган Тәртиптә һәм шушы Килешүдә билгеләнгән шартлары, максатлары һәм тәртибе нигезендә территориаль социаль яклау органы тарафыннан кабул ителгән карардан соң Җиткерүчегә грант бирергә һәм Җиткерүченең кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы хисабыннан 10 эш көне эчендә күчерергә.

4.2. Җиткерүче түбәндәгеләрне үтәү бурычын үз өстенә ала:

4.2.1. Татарстан Республикасында социаль хезмәт җиткерүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтелүнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән расланган тәртипләре нигезендә социаль хезмәт күрсәтелүгә мохтаҗ дип танылучы гражданнарга социаль хезмәтләр күрсәтергә.

4.2.2. Министрлык таләбе буенча шушы Килешүдә каралган шартларның үтәлүен тикшерү өчен кирәкле мәгълүматларны һәм документларны тапшырырга; Министрлыкка тапшырыла торган документларның һәм мәгълүматларның үз вакытында тапшырылуын, аларның тулы һәм дөрес булуын тәэмин итәргә.

4.2.3. Министрлыктан тиешле таләп алынган көннән соңгы, эш көннәрендә исәпләнүче 30 көнлек чорда Җиткерүчегә күчерелгән грантны Татарстан Республикасы бюджетына кайтарып бирергә, түбәндәге очракларда:

Җиткерүче тарафыннан төгәл булмаган мәгълүматлар тапшыру фактлары ачыкланганда;

Грант күләмен билгеләү буенча Җиткерүче һәм (яисә) Министрлык тарафыннан башкарылган исәпләүләрдә хаталар ачыкланганда;

грант бирелү шартлары үтәлмәгәндә.

4.2.4. Министрлык вәкилләренә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 29.12.2016 № 1046 карары белән расланган Тәртиптә һәм шушы Килешүдә билгеләнгән грант бирелү шартларының, максатларының һәм

тәртибенең үтәлешен, шулай ук тапшырылган мәгълүматларның дөрес булуын тикшереп торуга вәкаләт бирелгән бүтән органнарның вәкилләренә социаль хезмәтләрне Җиткерүчегә үтемлелекне тәэмин итәргә.

4.2.5. Җиткерүченең аталышы, юридик, фактик һәм почта адресы, банк реквизитлары һәм шушы Килешүнең 8 нче пунктында күрсәтелгән башка мәгълүматлары үзгәрүе турында тиешле үзгәреш барлыкка килгән көннән соңгы өч көн эчендә Министрлыкка хәбәр итәргә.

4.2.6. Министрлык, дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә грант бирүнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 29.12.2016 № 1046 карары белән расланган Тәртиптә һәм шушы Килешүдә билгеләнгән шартларын, максатларын һәм тәртибен бозулар ачыкланган очракта Җиткерүчегә күчерелгән грант акчалары (акчаның бер өлеше) Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән соңгы, эш көннәрендә исәпләнүче 30 көнлек чорда кайтарып бирелергә тиеш.

## V. Тарафларның җаваплы булуы

5.1. Тарафлар шушы Килешү буенча бурычларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен Россия Федерациясе законнары һәм шушы Килешү нигезендә җаваплы булалар.

5.2. Шушы килешүдә каралган бурычларның Җиткерүче тарафыннан үтәлү вакытылары узып киткәндә, Министрлык неустойка (штраф, пенялар) түләүне таләп итәргә хокуклы. Неустойка (штраф, пенялар) шушы Килешүдә каралган бурычларны үтәүнең уздырылган һәр көне өчен, бурычларны үтәү буенча шушы Килешүдә билгеләнгән вакыт узган көннән соңгы көннән башлап исәпләнә. Неустойканың (штрафның, пеняларның) күләме, әгәр дә шушы Килешүдә башкача каралмаса, неустойканы (штрафны, пеняларны) түләгән көнне грант суммасыннан Россия Федерациясе Үзәк банкының гамәлдә булган рефинанслау ставкасының 4/300 күләмендә билгеләнә.

Әгәр дә Җиткерүче күрсәтелгән шартларны үтәүнең вакыты узып китүнең җиңеп булмаслык көч аркасында яисә Министрлык гаебе белән барлыкка килүен дәлилли алса, неустойка (штраф, пенялар) түләүдән азат ителә.

5.3. Җиткерүче тарафыннан шушы Килешүнең 4.2.3 пунктында каралган грант акчасын ирекле рәвештә кайтарып бирү чоры бозылган очракта, Җиткерүче грант акчасын үз вакытында күчермәгән өчен Министрлыкка кайтарып бирелергә тиешле сумманың 0,1 проценты күләмендә, грант Җиткерүчедә булган һәр көн өчен, пенялар түли.

5.4. Җиткерүче тарафыннан тулы булмаган мәгълүматлар җиткерелү фактлары ачыкланган очракта, Җиткерүче, грант Җиткерүчедә булган һәр көн өчен (дөрес булмаган мәгълүматлар нигезендә Җиткерүче тарафыннан грант алынган көннән башлап һәм аларны фактта кайтарып бирү мизгеленә кадәр), кайтарып бирелергә тиешле грант суммасыннан неустойканы (штрафны, пеняларны) түләгән көндә Россия Федерациясе Үзәк банкының гамәлдә булган рефинанслау ставкасының 10/300 күләмендә пенялар өстәп, күчерелгән грантның артык өлешен кайтарып бирә.

## VI. Килешүнең гамәлдә булу чоры

6.1. Әлеге Килешү, шушы пунктның икенче абзацында күрсәтелгән очрактан кала, Тарафлар аңа имза куйган вакыттан башлап үз көченә керә һәм 20___ елның 1 февраленә кадәр гамәлдә була.

Җиткерүче социаль хезмәт җиткерүчеләр реестрыннан төшереп калдырылган очракта Килешү Җиткерүчене социаль хезмәт җиткерүчеләр реестрыннан төшереп калдырылган көннән соңгы егерме биш эш көне тәмамланганчыга кадәр гамәлдә була.

6.2. Бу Килешү бертигез юридик көчкә ия булган өч нөсхәдә төзелде, ике нөсхә – Министрлыкка, берсе – Җиткерүчегә.

## VII. Башка шартлар

7.1. Бу Килешүне үзгәртү Тарафлар инициативасы буенча язмача рәвештә, өстәмә килешү имзалау юлы белән гамәлгә ашырыла, өстәмә килешү әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып санала.

7.2. Тарафлар арасындагы бәхәсләр сөйләшүләр алып бару юлы белән, әгәр дә уртак килешүгә ирешелмәсә, суд тәртибендә хәл ителә.

7.3. Җиткерүче Министрлыкка һәм территориаль социаль яклау органына тапшырылган мәгълүматларның дөрес булуы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

7.4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт финанс контролен тәэмин итү буенча вәкаләтләр бүлеп бирелгән бүтән органнар тарафыннан грант бирелүнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 29.12.2016 № 1046 карары белән расланган Тәртиптә һәм шушы Килешүдә билгеләнгән шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешенә карата тикшерүләр гамәлгә ашырыла.

7.5. Шушы Килешүгә кул куеп, Җиткерүче Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт финанс контролен тәэмин итү буенча вәкаләтләр бүлеп бирелгән бүтән органнар тарафыннан грант алу шартларының, максатларының һәм тәртибенең Җиткерүче тарафыннан үтәлүенә карата тикшерүләр үткәрелүгә үзенең риза булуын раслый.

7.6. Грант акчасының хисап финанс елында файдаланылмаган өлеше Җиткерүче тарафыннан хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемепә кайтарып бирелергә тиеш.

## 8. Тарафларның юридик адреслары, банк реквизитлары һәм имзалары

Җиткерүче
*Оешманың тулы аталышы*
*Тулы почта адресы*
*банк аталышы*
*и-х/с*
*к/с*
*БИК*
*ИНН*
*КПП*
*ОГРН*
*Оешманың банк операцияләрен үткәргәндә кулланыла торган кыскартылган исеме*

Җитәкчесе
___________________________*Ф.И.А.*
М.У. (эш бирүче өчен
Россия Федерациясе законнарында
мөһер булдыру бурычы билгеләнгән булса)

Вәкаләтле орган
Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы
420044, Казан ш., Волгоград ур., 47 й.
Бүлек – Татарстан Республикасы МБ
и-х/с 40201810900000000002
БИК 049205001, ИНН 1657069000, КПП 165701001
ТР буенча ФКИ (ТР ФМ ш/с 02092011000, ТР Хезмәт министрлыгы, ЛБ 007160002 – ХСЯклау мин)
ОГРН 1071690050299
Җитәкчесе
______________________________*Ф.И.А.*
М.У. (эш бирүче өчен
Россия Федерациясе законнарында
мөһер булдыру бурычы билгеләнгән булса)

Социаль хезмәтләр күрсәтелүгә бәйле рәвештә чыгымнарны компенсацияләүгә (түләүгә) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирелү турында килешүгә
1 нче кушымта

Рәвеше

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының_______
_________________________муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) социаль яклау идарәсе (бүлеге) башлыгына___________________________

______социаль хезмәтләр җиткерүчедән вазифасының атылышы,

______________________________________
социаль хезмәтләр җиткерүчедән гариза тапшыручының Ф.И.А.

Субсидия рәвешендә грант күчерелү турында
**ГАРИЗА**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында социаль хезмәт җиткерүчеләр реестрына кертелгән, ләкин дәүләт биремен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәт җиткерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының көчен югалтуын тану турында" 2016 елның 29 декабрендәге 1046 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт җиткерүчеләр реестрына кертелгән, ләкин дәүләт биремен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәт җиткерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибе нигезендә ______________________________________________________
(социаль хезмәтләрне күрсәтү чоры күрсәтелә)
күрсәтелгән социаль хезмәтләр өчен_____________________________________________
_______сум_______тиен күләмендә субсидия рәвешендә грант күчерүне сорыйм.

Шушы гаризада һәм аңа теркәлә торган документларда булган мәгълүматларның дөрес һәм тулы булуын раслыйм.

Төгәл булмаган мәгълүматларны һәм документларны тапшырган өчен җаваплылык турында кисәтелдек.

Грант алу максатларында төгәл булмаган мәгълүматлар тапшырылган очракта, шулай ук

хата ачыклану нәтиҗәсендә күчерелгән грантның артык суммасын Татарстан Республикасы бюджеты керемен кайтарып бирергә мәҗбүр булуыбыз турында кисәтү ясалды.

Бу гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны карап тикшерү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматларны түбәндәге адрес буенча җибәрүне сорыйм (кирәклесен V тамгасы белән билгеләргә):

Почта ☐

электрон почта ☐

Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

| № п/п | Документларның аталышы | Саны | |
|---|---|---|---|
| | | данә | бит |
| 1. | | | |
| 2. | | | |
| 3. | | | |
| 4. | | | |
| 5. | | | |
| 6. | | | |
| 7. | | | |
| 8. | | | |
| 9. | | | |
| 10. | | | |

"____" _______________ 20 ___ ел. ____________________ ______________________________

(дата) (гариза бирүченең имзасы) (имзаның аңлатмасы)

М.У. (Россия Федерациясе законнарында эш бирүче өчен мөһер булдыру бурычы билгеләнгән очракларда)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

**Язу-белдерүнамә**

Гариза һәм документлар кабул ителде (кемнән): ________________________________________

Гаризаны теркәү номеры

_______________

Гаризаны һәм документларны кабул итү датасы

___________________________

(көне, ае, елы)

Социаль яклау идарәсе (бүлеге) хезмәткәренең имзасы

___________________________

Имзаның аңлатмасы

___________________________

Социаль хезмәтләр күрсәтелүгә бәйле рәвештә чыгымнарны компенсацияләүгә (түләүгә) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирелү турында килешүгә

2 нче кушымта

Рәвеше

## ______________________ СОЦИАЛЬ ХЕЗМӘТЛӘР АЛУЧЫЛАР РЕЕСТРЫ

(социаль хезмәтләр житкерүченең аталышы)

## ______________ӨЧЕН

(чорын күрсәтергә)

| № п/п | Социаль хезмәтне алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта) | Паспорт белешмәләре (сериясе, номеры, бирелү датасы, кем тарафыннан бирелгән) | Теркәлү урыны буенча адресы | Социаль хезмәтләр күрсәтелү турында шартнамә реквизитлары (датасы, номеры)* | Хосусый программа реквизитлары (бирелү датасы, номеры) | Социаль хезмәтнең аталышы | Хосусый программа буенча социаль хезмәтләр күрсәтелү турында шартнамәдә каралган социаль хезмәтләр күләме (бер.) | Социаль Хезмәтнең күрсәтелгән фактик күләме (бер.) | Тәртип нигезендә социаль хезмәт өчен социаль хезмәт алучы тарафыннан түләнүче сумма исәпләмәсе (сум) | ТР МК "Социаль хезмәтләр күрсәтелгән өчен түләү күләмен һәм аны алу тәртибен раслау турында" 29.11.2014 № 927 карары нигезендә социаль хезмәтләр алучы түләгән сумма |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |

Җитәкче _______________ /_______________________ "____" ______________ 20__ел.
(имза) (имзаның аңлатмасы) (дата)

Баш бухгалтер _______________ /_______________________/ "____" ______________ 20__ел.
(имза) (имзаның аңлатмасы) (дата)

*ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтелгән очракта бу графада сызык куела.

Социаль хезмәтләр күрсәтелүгә бәйле рәвештә чыгымнарны компенсацияләүгә (түләүгә) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирелү турында килешүгә

3 нче кушымта

Рәвеше

**БЕЛЕШМӘ-ИСӘПЛӘМӘ**

Татарстан Республикасы бюджетыннан ______________________________ субсидия рәвешендә грант күчерелүгә
(социаль хезмәтләр житкерүченең аталышы)

______________________ ӨЧЕН
(чорын күрсәтергә)

| № п/п | Социаль хезмәтнең аталышы | Социаль хезмәтләргә житкерүче тарафыннан расланган тарифлар, яисә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан расланган тарифлар (сум) | Хосусый программа буенча социаль хезмәтләр күрсәтелү турында шартнамәдә каралган социаль хезмәтләр күләме (бер.) | Социаль хезмәтләрнең хосусый программа буенча социаль хезмәтләр күрсәтелү турында шартнамәсендә каралган күләмнән чыгып исәпләнгән бәясе (сум) | Социаль хезмәтләрнен, социаль хезмәтләр алучыларга фактта күрсәтелгән күләме (бер.) | Социаль хезмәтнең фактта күрсәтелгән социаль хезмәтләр күләменнән чыгып исәпләнгән бәясе (сум) | ТР МК "Социаль хезмәтләр күрсәтелгән өчен түләү күләмен һәм аны алу тәртибен раслау турында" 29.11.2014 № 927 карары нигезендә социаль хезмәтләр алучы түләргә тиешле сумма | Күчерү өчен грант (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | гр.5=гр.3*гр.4 | 6 | гр.7=гр.3*гр.6 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |

Җитәкче_________________________ /____________________ "__" ____________________ ел.
вазыйфасы (Ф.И.А.) (имза) (гаризаны тутыру датасы)

Баш бухгалтер ________________________________ /____________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

М.У. (эш бирүчегә карата Россия Федерациясе законнарында мөһер булдыру бурычы билгеләнгән булса)

Вәкаләтле орган тамгасы (кирәклесен v тамгасы белән билгеләргә): ☐грант күчерергә; ☐ грант күчерүдән баш тартырга

Социаль яклау идарәсе (бүлеге) башлыгы________________ (______________________) "__" __________________ ел.
(имза) (Ф.И.А.) (карар кабул итү датасы)

Исәпләмәне тикшерде ______________________ / ______________________________________ "__" ___________________ел.
вазыйфасы (имза) (Ф.И.А.) (исәпләмәне тикшерү датасы)

Татарстан Республикасы
Хезмәт һәм социаль яклау
министрлыгының бүлек башлыгы ________________ (____________________) "__" ______________________ел.
(имза) (Ф.И.А.) ( дата )

Социаль хезмәтләр күрсәтелүгә бәйле рәвештә чыгымнарны компенсацияләүгә (түләүгә) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирелү турында килешүгә
4 нче кушымта

Рәвеше

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының
________________________________
____________________муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) социаль яклау идарәсе (бүлеге) башлыгына

Татарстан Республикасында социаль хезмәт җиткерүчеләр реестрына кертелгән, ләкин дәүләт биремен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр җиткерүчегә субсидия рәвешендә грант күчерү (күчерүдән баш тарту) турында
КАРАР

20____елның _______№ ____

_______________________________________________________субсидия рәве-
(социаль хезмәтләр җиткерүченең аталышы)
шендә грант күчерелү турында_________№_____гаризасы карап тикшерелде.
(дата)
___________________________________________________________________
(социаль хезмәт җиткерүченең аталышы)
_________________сум күләмендә________________________________________
(субсидия рәвешендә грант күчерергә
_____________________________________________________________________.
(субсидия рәвешендә грант күчерүдән баш тартырга)

_____________________________________________________________________
(субсидия рәвешендә грант күчерүдән баш тартканда, баш тартуның сәбәбе күрсәтелә)

_________________________________
(муниципаль районындагы (шәһәр округындагы))
социаль яклау идарәсе (бүлеге)
башлыгы _______________ _______________"__" _______________ ел.
(имза) (Ф.И.А.) (кул кую датасы)
Белгеч ___________ ____________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Социаль хезмәтләр күрсәтелүгә бәйле рәвештә чыгымнарны компенсацияләүгә (түләүгә) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия рәвешендә грант бирелү турында килешүгә
5 нче кушымта

Рәвеше

Раслыйм:
Министр урынбасары
___________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

"__" _________________ ел.
(кул кую датасы)

________________________________________территориясендә эшчәнлек
(муниципаль район (шәһәр округы))
башкаручы социаль хезмәтләр җиткерүчегә субсидия
рәвешендә грант күчерүгә
**№________ РЕЕСТР**

________________________ **өчен**
(чорын күрсәтергә (ай, квартал, ел)

| Хезмәтләр җиткерүченең аталышы | Хезмәтләрне җиткерүченең (гариза бирүченең) банк реквизитлары | Күчерү өчен грант күләме (сум) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

___________________________________
(муниципаль районындагы (шәһәр округындагы))
социаль яклау идарәсе (бүлеге)
башлыгы __________________ _________________"__" _________________ ел.
(имза) (Ф.И.А.) (кул кую датасы)

Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының эшчәнлегенең
әлеге юнәлешен тикшереп торучы
бүлек башлыгы __________________ _________________"__" _________________ ел.
(имза) (Ф.И.А.) (кул кую датасы)